Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Түбән Кондрата авыл җирлеге Советы

# КАРАР

«28» июн ь 2024 ел № 49/2

Физик затларның
җир салымы һәм мөлкәтенә
салым буенча бурычларын
түләтүгә өметсез дип тануның
өстәмә нигезләре турында

Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясының 3 пункты нигезендә, Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлеге Уставы белән, Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. 2024 елның 1 гыйнварына физик затларның җир салымы һәм мөлкәтенә салым суммалары буенча аерым салым түләүчеләргә исәпләнгән, түләтү һәм (яки) түләтү түбәндәге нигезләр буенча мөмкин булмаган бурыч түләтүгә өметсез дип таныла:
1.1. варислар мирас хокукыннан баш тарткан, варислар булмаган яки мирас ачылганнан соң бер ел эчендә мирасны кабул итмәгән очракта үлгән яки үлгән дип игълан ителгән физик затларда бурычлар булу;
1.2. 2024 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдән чыгарылган җирле салымнар буенча оешмаларга яки шәхси эшмәкәрләргә исәпләнгән бурычлар булу;
1.3. физик затларда Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу.
2. Җир салымы һәм физик затларның мөлкәтенә салым суммалары буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тануның өстәмә нигезләре булуын раслаучы документлар булып:
2.1. әлеге карарның 1 пунктының 1.1 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:
а) физик затның яшәү урыны буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;
б) үлем белән бәйле рәвештә салым органнарында физик затны исәптән төшерү турында мәгълүмат;

в) мирас хокукы турында таныклык бирү турында мәгълүмат булмау турында салым органы белешмәсе;
2.2. әлеге карарның 1 пунктының 1.2 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда:
а) оешма, шәхси эшмәкәр, шәхси эшмәкәр статусын югалткан физик зат исәпкә алынган урын буенча салым органының бурыч суммасы турында белешмәсе;
б) салым гамәлдән чыгарылган норматив хокукый акт (исеме, датасы, номеры) турында мәгълүмат;
2.3. әлеге карарның 1 пунктының 1.3 пунктчасында күрсәтелгән нигез булганда, салым органының 500 сумнан артмаган бурыч булуы турында белешмәсе.
3. Әлеге карарны билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга.
4. Әлеге карар аның басылып чыккан (халыкка чыгарылган) көненнән үз көченә керә.
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Чистай муниципаль районы Түбән Кондрата авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районы
Түбән Кондрата авыл җирлеге башлыгы С.В.Васильев